**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге составына керүче Колыш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

20 октябрь, 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 20 октяберендә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены беркетмәсе тәзелде:

«2023 елда яшәү урыны буенча Боерган авыл җирлеге Колыш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз)сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Колыш авылы Тельман урамы буйлап юл төзеклөндерү;
- Колыш авылы Тельман урамы буйлап ясалма юл тигезсезлеге эшләтү;
- Колыш авылы чишмәсен төзеклөндерү өчен төзелеш материаллары сатып алуны хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме.”

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 120 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 63 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 63 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Колыш авылы гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2023 елда яшәү урыны буенча Боерган авыл җирлеге Колыш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә

һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне:

- Колыш авылы Тельман урамы буйлап юл төзекләндерү;
- Колыш авылы Тельман урамы буйлап ясалма юл тигезсезлеге эшләтү;
- Колыш авылы чишмәсен төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу» буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Колыш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Колыш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Боерган авыл җирлеге Башкарма комитеты
Җитәкчесе вазифаларын вакытлыча башкаручы Ф.В.Шәвәлиев